**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышев урамы, 23нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34

e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

2022 елның « 03 » феврале 195 номер

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре, Шмидт урамы адресы буенча урнашкан, кадастр номеры 16:24:170126:516 булган җир кишәрлеген яңадан бүлү юлы белән территорияләрне ызанлау проектын әзерләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 41, 43, 45нче маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә, территорияләрне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, шул исәптән планлаштыру структурасы элементларын бүлеп бирү, җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү, капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү максатларында, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре, Шмидт ур., 16:24:170126:516 кадастр номеры белән җир кишәрлеген яңадан бүлү юлы белән территорияне межалау проектын әзерләүгә керешергә.

2. Проектның эчтәлеген Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексының 43 статьясы нигезендә билгеләргә.

3. Ачык тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) үткәрүне исәпкә алып, проектны әзерләү вакытын 2021 ел ахырына кадәр билгеләргә.

4. Әлеге карар басылып чykканнан соң ундүрт көн эчендә физик һәм юридик затларга территорияне межалау проектының тәртибе, сроклары һәм эчтәлеге турында тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрергә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге проектны әзерләү эшләрен оештыруны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура бүлегенә йөкләргә.

6. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

.

**Җитәкче** **А.А. Новиков**